УДК 297.1

# РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН Ш. МӘРҖАНИНЕҢ КАЙБЕР ЯЛГЫШЛАРЫ ХАКЫНДА

***А.М. Гайнетдинов***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*aydargm@yandex.ru*

Мәшһүр татар галиме, дин белгече, мөфти Ризаэддин Фәхреддин, галим Шиһабетдин Мәрҗанидә турыдан-туры укымаса да, аның китаплары аша күп белем алган. Үзенең *«Асар»* («Әсәрләр») дигән фундаменталь хезмәтендә ул Мәрҗани хакында бик күп язган. Анда аның шәҗәрәсе, шәхесе, балалары, кыяфәте, остазлары, шәкертләре, әсәрләре, хаталары һ.б хакында бай мәгълүмат китерелгән. Ризаэддин хәзрәт фикеренчә, Шиһаб хәзрәт Россия мөселманнары арасында шәйхелислам Ибне Тәймия эшчәнлеген яктырткан иң беренче кеше булган. Р. Фәхреддин, Мәрҗанинең сүзләренә сукырларча ышанмыйча, хаклык эзләп, галим күтәргән һәр мәсьәләне җентекләп тикшерергә тырышкан. Бөек татар галименең һәр фикере аның өчен зур әһәмияткә һәм хөрмәткә ия булса да, Р. Фәхреддин аның кайбер хаталарын ачыклый алган. Бу бигрәк тә гарәп галиме Ибне Тәймиянең инану мәсьәләләре турындагы өйрәтмәләренә кагылган, чөнки аны кайберәүләр Аллаһны гәүдәләндерүдә, Аңа билгеле бер урын билгеләүдә, шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәрнең каберен зиярәт итүне хәрам дип санауда гаепләгәннәр. Р. Фәхреддин, гарәп галименең китапларын җентекләп өйрәнгәннән соң, әлеге шәхескә яла ягуларын һәм сүзләрен дөрес аңламауларын ачыклаган һәм шуларны төзәткән, үз фикерләрен башка зур галимнәрнең сүзләре белән ныгыткан. Шул ук вакытта, Риза хәзрәт, остазына каты бәрелмичә, әдәп белән генә эш иткән һәм шунда ук аны акларга да тырышкан. Аның фикеренчә, Мәрҗани Ибне Тәймиянең хезмәтләрен турыдан-туры өйрәнмәгәнгә, мөселман философы әд-Дәүванигә һәм гарәп язучысы әл-Яфигыйга нигезсез ышанганлыктан, шундый хаталануларга дучар булган. Р. Фәхреддин, үзенә хәтле мөфти булган Г. Баруди кебек үк, Ибне Тәймиянең фикерләре белән тулысынча килешкән, хезмәтләрен җентекләп өйрәнгән, хәтта әлеге шәхесне үзенә үрнәк итеп тоткан һәм беркемгә дә аның исемен хаксыз рәвештә пычратуга юл куймаган.

**Төп төшенчәләр:** Ризаэддин Фәхреддин, Мәрҗани, хаталар, Ибне Тәймия, әд-Дәүвани, әл-Яфигый, *«Асар»*

**Сылтама ясау өчен:** Гайнутдинов А.М. Р. Ризаэддин Фәхреддин Мәрҗанинең кайбер ялгышлары хакында // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 284–292. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.284-292

Мөфти Р. Фәхреддин, атаклы галим Шиһабетдин Мәрҗанидән белем алмаса да, аның хезмәтләреннән күп гыйлем, файда, тәҗрибә туплый алган. Шул исәптән аның тәэсире, йогынтысы аркасында, Риза хәзрәт иң могтәбәр дин галимнәребезнең берсе буларак формалашкан, безгә дин, тарих, әдәбият, педагогика һ.б. буенча бәяләп бетергесез бик зур мирас калдырган. Ш. Мәрҗани аның үзе турында «Бу егет өметле. Мәсләгендә дәвам итсә, яхшы хезмәт итәр!» дип әйтүе (Шәрәф 1915: 181) дә Р. Фәхреддинне хәзрәтне югары үрләр яуларга канатландырган булса кирәк.

Мәгълүм ки, атаклы *«Асар»* («Әсәрләр») китабында ул бик күп шәхесләр хакында язып калдырган. «Асар» сүзен төрле галимнәр төрлечә тәрҗемә итә. Мәсәлән, «эзләр», «гамәлләр» һ.б. Тик безнең фикеребезчә, «асар» сүзе «әсәрләр» дип тәрҗемә ителергә тиеш. Беренчедән, әлеге хезмәт Р. Фәхреддингә төрле кешеләр тарафыннан җибәрелгән язмалардан яки әсәрләрдән тора, ягъни аңа шәҗәрәләр, кабер ташлары язмалары, хатирәләр, риваятьләр җибәрелгән. Шул әсәрләрне туплаганнан һәм эшкәрткәннән соң, галим теге яисә бу кеше турында мәгълүмат биргән.

*«Асар»*да китерелгән шәхесләр арасында иң күләмле һәм иң күп мәгълүмат бирелгән кеше – Ш. Мәрҗани. Аның хакында Риза хәзрәт 50 бит язган, ягъни кульязмасының 125 битеннән алып 149 битенә кадәрлесе әлеге шәхес хакындагы мәгълүматлардан гыйбарәт (Фәхреддин 2010: 151–195). Анда Мәрҗанинең шәҗәрәсе, шәхесе, балалары, кыяфәте, остазлары, шәкертләре, әсәрләре, хаталары һ.б хакында бай мәгълүмат китерелгән.

Нинди генә зур галим булмасын, кешенең барыбер нindидер ялгышулары була. Шул исәптән Мәрҗанинең дә бераз хаталары булган, әлбәттә. Әгәр дә аның эпиграфика өлкәсендәге хезмәтләрен тикшерсәк, кайбер ташлардагы текстларны хаталы укуын күрергә мөмкин. Мәрҗанинең мондый төр ялгышлары хакында эпиграфистлар Н. Ашмарин, Г. Рәхим, Һ. Йосыпов язып калдырганнар. Дин тарихы өлкәсендәге аз гына хаталарын исә исламны һәм тарихны гаять яхшы белгән Р. Фәхреддин күреп алган һәм төзәткән. Гомумән, ул, дөрес сүзләр кем тарафыннан әйтелсә дә – кабул ителергә һәм ялгыш фикерләр, кемнән чыкса да – ташланырга тиешле, дип санаган һәм болай язып калдырган: «Пәйгамбәрләрдән башкаларны гөнаһсыз дип танымаганыбыз өчен, һичкемнең бөтен сүзен дөрес һәм барлык фикерен туры, дип дәгъва кылырга мөмкин түгел. Никадәр галим һәм акыллы булмасын, һәркемдә берәр хата була ала» (Фәхреддин 2018: 177; кайбер төзәтмәләр белән).

Ризаэддин хәзрәт фикеренчә, Русия мөселманнары арасында шәйхелислам Тәкыеддин Әхмәд Ибне Тәймияне (1263–1328) өйрәнүчеләрнең иң беренчесе Ш. Мәрҗани булган. Шиһаб хәзрәт үзенең *«Әл-газбел-фурат вәл-маэз-зөлален-нәкыйгъ ли-голләти роувамил-ибраз ли-әсрари шәрхил-Җәлал»* хезмәтендә түбәндәгечә язган:

> «Әбү әл-Габбас Әхмәд Ибне Тәймия хәнбәлиләрнең “җәһәт” һәм “мәкән” турында әйткән фазыйләтле затларыннан, хәдис әһелләреннән. Аның тоткан юлы “урын”ны “гареш” дип раслаудан гыйбарәт

булгач, аның “Галәм бөтен өлешләре белән барлыкка килгән” дип әйтүе мөмкин булмый, шуңа шәхесләрнең [аерым өлешләрнең] барлыкка килүе белән генә канәгать кала» (Җәлал әд-Дәүвани 1873: 40); (Фәхреддин 2018: 127).

Шулай итеп, Мәрҗани аның Аллаһка урын һәм тараф бирүенә ишарә иткән. Ризаэддин хәзрәт моңа каршы чыгып, чынлыкта, бу сүзнең ялган булуын һәм Ибне Тәймиянең алай дип сөйләмәвен үзенең *«Асар»* һәм *«Ибне Тәймия»* китапларында аңлаткан.

Р. Фәхреддин олуг дин галиме Ибне Тәймиянең басылган бөтен китапларын бик игътибар белән, җентекләп тикшереп чыккан, әмма бер җирдә дә Мәрҗанинең хаклыгына ишарә итә торган нәрсә тапмаган, бәлки, киресенчә, *«Муафәка сарих әл-мәгъкуль ли-сахих әл-мәнкуль»* хезмәтендә Ибне Тәймия мөҗәссимнәрне (Аллаһны гәүдәләндерүчеләрне) бик нык тәнкыйтьләгәнлеген ачыклаган. Ибне Тәймия Аллаһның Үзенә мәгълүм булган рәвештә «югары булу», «күтәрелү» кебек сыйфатларын таныган, ләкин, Риза хәзрәт язганча, бу әле Аллаһка конкрет урын билгеләүне аңлатмый (Фәхреддин 2018: 128).

*«Шура»* журналында Р. Фәхреддингә Ибне Тәймиянең Аллаһны гәүдәләндерүе хакында сорау биргәч, ул:

«Максатыгыз Ибне Тәймия хакында дөрес бер фикер хасил итү булса, читләр тарафыннан сөйләнгән сүзләргә ышану җирендә турыдан-туры үз әсәрләрен укыгыз. Шулвакыт белерсез ки, Ибне Тәймия мондый нәрсәләрдән пакь», – дип җавап биргән (Риза казый фәтваләре 2019: 21).

Р. Фәхреддин Мәрҗани улы Борһанетдиннән ни өчен атасының шулай язганлыгын ачыкламакчы булган, әмма ул моны берничек тә аңлата алмаган. Ризаэддин хәзрәт Мәрҗанигә мөселман философы Җәлаледдин Мөхәммәд бине Әсгадь әд-Дәүвани (1427–1512) сүзләре тәэсир итүен чамалаган, тик Борһанетдин моны кире каккан. Тарихчы Д.Ә. Шәһабиев әлеге мәсьәләне тикшергән һәм, чыннан да, Мәрҗанинең үз хезмәтләрендә, кайбер вак аермалар белән булса да, нигездә, әд-Дәүвани һәм Габдулла бин Әсгадь әл-Яфигый (1298–1367) сүзләрен китергәнен ачыклаган (Шагавиев 2019: 775–791).

Шунысын әйтмичә калып булмый, кайбер тарихчылар, чыганакларны үзләренчә аңлап, бөтенләй булмаган нәрсәләрне бар итеп, арттырып язалар. Мәсәлән, искә алып узган мөхтәрәм тарихчы, әшгариләр һәм матуридиләр позициясеннән карап, югарыда китерелгән цитата Ибне Тәймияне бидгатьче итеп характерлый, дип язган (Шагавиев 2019: 778). Тик Мәрҗани аны бидгатьче дип атамаган, алай тәнкыйтьләмәгән, ул гына түгел, әшгариләр һәм матуридиләр кебек кәлям әһелләре позициясендә тормаган. Киресенчә, Мәрҗани байтак хезмәтләрендә әшгариләрнең гакыйдәсен бик нык тәнкыйтьләгән, хәтта аларны кешеләрне адаштыруда гаепләгән. Матуридиләргә килгәндә, Мәрҗани бер хезмәтендә дә аларга ияргергә кушмаган. Шуңа күрә атаклы дин галиме Әхмәдһади Максуди

Ш. Мәрҗанинең матуридиләргә бернинди катнашы булмаганлыгын белдереп: «Игътикадта әшгари түгел, матүриди дә булмады, мөгътәзили яки шигый да түгел иде, ләкин Мәрҗани иде», – дип язган (Максуди 1915: 427–428). Мәрҗани *«Әл-газбел-фурат»* китабында Ибне Тәймия хакында фәкать бер факт кына китергән, ләкин үз мөнәсәбәтен алай кискен белдермәгән, киресенчә, аның әле Ибне Тәймияне фазыйләтле затлардан санаганлыгы ачык аңлашыла. Фән галименең шундый сәер интерпретация бирүе, субъектив рәвештә фикер йөртеп, теге яки бу нәрсәне бидгать дип атавы һич аңлашылмый. Безнең уебызча, тарихчыга бу очракта, объектив рәвештә карамыйча, теге яисә бу шәхесне, инквизиция чорындагы кебек, бидгать эш кылуда гаепләү, кемнедер бидгатьче дип атау килешми.

Р. Фәхреддиннең *«Асар»* хезмәтендә урын алган түбәндәге сүзләреннән остазын акларга тырышуы сизелә:

> «Соңгы тикшеренүләреннән мәгълүм булуга күрә, Мәрҗани үзе арадашчысыз Ибне Тәймия әсәрләрен күрә алмаган. Аның заманында басылып өлгермәгәннәр. Бу турыдагы сүзе әд-Дәванигә ышануыннан булган» (Фәхреддин 2010: 185).

Чыннан да, Мәрҗани турыдан-туры Ибне Тәймиянең әсәрләре белән таныш булмаган, аның китапларын укымаган (Шагавиев 2019: 790), шуңа күрә ул, әлеге философ сүзләренә ышанып, Ибне Тәймия хакында дөреслеккә туры килмәгән сүзләр язган. Багдад мөфтие Сәед Ногман Хәйреддин әл-Әлуси *«Җәләъ әл-гайнәйни фи мухәкәмәт әл-әхмәдәйн»* китабында Ибне Тәймиянең Аллаһны гәүдәләндерүе турындагы хәбәрне яла ягу дип атаган һәм иң беренче булып бу яланы әд-Дәвани чыгарганлыгын белдергән (Фәхреддин 2018: 99). Хәнәфиләр мөфтие Шиһабеддин әл-Әлуси дә Ибне Тәймиянең, киресенчә, мондый гаепләрдән пакь булуын язган һәм әд-Дәванине һәм аның кебекләрне иң надан кешеләр дип атаган (Фәхреддин 2018: 99).

Шулай ук Ш. Мәрҗани, гарәп язучысы әл-Яфигый сүзләренә таянып, *«Вәфиятел-әсляф вә тәхийятел-әхляф»* хезмәтендә Ибне Тәймиянең Мөхәммәд пәйгамбәрнең каберен зиярәт кылудан тыюын язган (Шагавиев 2019: 785). Риза хәзрәт хәбәр иткәнчә, Мәрҗани бу очракта да нык ялгышкан, чөнки Ибне Тәймия моны тыймаган, бәлки фәкать каберен зиярәт кылу нияте белән сәфәргә чыгарга кушмаган, әгәр дә башка максат белән булса, Мәдинә шәһәренә килгән кешенең пәйгамбәр каберен зиярәт итүен күркәм бер гамәл итеп санаган (Фәхреддин 2018: 46). Болар – әлбәттә, икесе ике нәрсә. Мәрҗанинең бу сүзләре ялган булуы мөфти әл-Әлуси сүзләреннән дә ачык күренә (Фәхреддин 2018: 100). Күп ислам галимнәре, пәйгамбәрнең «Өч мәчеттән башкаларга сәфәр кылынмас: [болар] "әл-Хәрам", "әл-Әкъса" һәм минем мәчетем» хәдисенә таянып, Мөхәммәд галәйһиссәламнең каберен зиярәт итү өчен генә сәфәргә баруны тыйганнар. Мәсәлән, шундыйлардан мәшһүр галим Имам Мәликне атарга мөмкин (Фәхреддин 2018: 47). Шунысы кызык: Мәрҗани әл-Яфигыйның сүзләрен тулысынча күчереп язмаган, чөнки бөтен фикерләрен дә

кабул итмәгән, күрәсең. Мәсәлән, гарәп язучысы Ибне Тәймияне төрмәгә сөнниләр (әһле сөннәт) мәзһәбенә каршы килгәне өчен утыртканнарын язса да, Мәрҗани бу сәбәпле зинданга ябылуын махсус төшереп калдырган (Шагавиев 2019: 785–786). Димәк, ул аны барыбер сөнниләр (әһле сөннәт вәл-җәмәгать) рәтенә керткән, кайбер дин әһелләре шикелле галимне «тәкфир» кылмаган (ислам диненнән чыгармаган) һәм аның күп фәннәрдә югары дәрәҗәгә ирешүен таныган.

Мәрҗанинең шәкерте булган күренекле галимебез Галимҗан Баруди да Ибне Тәймиянең мәсләген кабул иткән булган. Бу аның Ризаэддин хәзрәткә хат белән язылган түбәндәге сүзләреннән ачык аңлашыла:

> «Ибне Тәймия хәзрәтләре хакында яхшы фикердә булучы элекке гасырларда Русиядә, ихтимал ки, [мин] фәкыйрь бер ялгызы гына булгандыр. Соңрак вакытларда бу турыда сезнең дус булуыгызны уйлый идем. Ибне Тәймия мәсләге, гомумән, гүзәл. 1872 милади елда гадәтемчә һәм теләгәнемчә күпме әсәре аркылы һәм соңрак та әлеге хәзрәт әсәрләренең үзеннән файда күрдем. Дошманнары тарафыннан китерелгән бәхәсләрнең күбесе, минем уемча, нигезсез» (Фәхреддин 2018: 130–131).

Димәк, Г. Баруди да Ибне Тәймиягә тагылган ялаларны нигезсез дип тапкан һәм *«Әд-дин вә әдәб»* журналында аның күп кенә карашларын куәтләгән.

Шулай итеп, Р. Фәхреддин, төпченүчән тарихчы һәм олуг дин галиме буларак, һәрвакыт хаклыкка ирешергә тырышкан, коры сүзләргә генә ышанмаган. Теге яки бу галим хак сүз әйтсә – Риза хәзрәт аны күкләргә чөеп мактаган, ялгышуын ачыкласа – олы дәрәҗәсенә карамыйча, бернәрсәдән дә курыкмыйча, үз сүзен әйткән, дөресләгән, какшамас дәлилләрен китергән, Хәтта Мәрҗани кебек зур галимнең фикерләрен дә ул башта ныклап тикшергән һәм, нәтиҗәдә, зур булмаган кайбер хаталарын ачыклый алган һәм аларны төзәткән, үз фикерләрен башка зур галимнәрнең сүзләре белән ныгыткан. Шул ук вакытта, Р. Фәхреддин, остазына каты бәрелмичә, әдәп белән генә эш иткән һәм шунда ук аны акларга да тырышкан. Аның фикеренчә, Мәрҗани Ибне Тәймиянең хезмәтләрен турыдан-туры тикшермәгәнгә, башка кешеләрнең сүзләренә нигезсез ышанганга күрә, шундый хаталануларга дучар булган. Мөфти Р. Фәхреддин, үзенә хәтле мөфти булган Г. Баруди кебек үк, Ибне Тәймиянең фикерләре белән тулысынча килешкән, хезмәтләрен җентекләп өйрәнгән, хәтта әлеге шәхесне үзенә үрнәк итеп тоткан һәм беркемгә дә аның исемен хаксыз рәвештә пычратуга юл куймаган.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Җәлал әд-Дәүвани 1873 – Җәлал әд-Дәүвани вә хашияи Хәлхали вә һамишендә хашияи Мәрҗани. Истанбул: Әсгадь әфәнде матбагасы. 1291/1873.

Максуди 1333 (1915) – Максуди Ә. Дамелла Мәрҗани хәзрәтләре // Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матбагасы (Нәшире Салих бине Сабит Гобәйдуллин), 1333 (1915). Б. 427–435.

Риза казый фәтваләре 2019 – Риза казый фәтваләре / Төз. А.М. Гайнетдинов. Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019.

Фәхреддин 2010 – Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010.

Фәхреддин 2018 – Фәхреддин Р. Ибне Тәймия. М.: Форум, 2018.

Шәрәф 1915 – Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матбагасы (Нәшире Салих бине Сабит Гобәйдуллин), 1333 (1915). Б. 2–193.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Шагавиев Д.А. Образ шейха Ибн-Таймиййи в трудах Шихабуддина Марджани // Минбар. Исламские исследования. 2019. № 12. С. 775–796.

**Автор турында белешмә:** Гайнетдинов Айдар Марсиль улы – филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының ТР халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); aydargm@yandex.ru

*Редакциягә керде 02.06.2020* *Басылуга кабул ителде 02.11.2020*
*Басылды 25.11.2020*

## RIZAEDDIN FAKHREDDIN ON MARJANI'S FEW MISTAKES

***A.M. Gainutdinov***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*aydargm@yandex.ru*

Although Mufti Rizaeddin Fakhreddin, he did not study under Shihabuddin Marjani, he gained much knowledge through his books. In his fundamental work, *"Asar"* ("Works"), he dedicated 50 pages to him, which provides rich information about his family tree, personality, children, appearance, mentors, students, books, mistakes, etc. According to Rizaeddin Hazrat, Marjani was the very first scholar among

Muslims of Russia who studied the activities of Sheikh al-Islam Ibn Taymiya. Fakhreddin, as a painstaking historian and theologian, always tried to reach the truth. He did not blindly trust Marjani's arguments; instead, he tried to study and analyze every question that he raised. Although the opinion of such a great Tatar scientist as Shihabuddin Marjani was authority for him, he revealed some errors in his works. One such issue was the creed of Ibn Taymiya, whom some accused of asserting God's corporeality and the physical presence of God in a particular place, and the ban on visiting the grave of the Prophet Muhammad. Fakhreddin, having carefully studied his books, found out that the scientist was slandered and misunderstood. He cited his arguments and other scholars' arguments on this issue. According to Fakhreddin, Marjani made some incorrect statements because he did not directly study the works of Ibn Taymiya, but instead relied on the Muslim philosopher Dawwani and included his quotes in his books. Simultaneously, Fakhreddin politely pointed out these errors to Marjani and immediately tried to justify him. Mufti Fakhreddin, like another Mufti Galimjan Barudi, studied the books of Ibn Taymiya, agreed with his views, even set this scientist as an example, and did not allow anyone to stain his name unfairly.

**Keywords:** Rizaeddin Fakhreddin, Marjani, mistakes, Ibn Taymiya, ad-Dawwani, al-Yafi'I', *"Asar"*

**For citation:** Gainutdinov A.M. Rizaeddin Fäkhreddin Märjanineñ kayber yalgyshlary khakynda [Rizaeddin Fakhreddin on Marjani's Few Mistakes]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2020, vol. 5, no. 2, pp. 284–292. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.284-292

REFERENCES

Shagaviev D.A. Obraz sheikha Ibn-Taimiyyi v trudakh Shihabuddina Marjani [The Image of Sheikh Ibn-Taimiyyah in the Writings of Shihab al-Din al-Marjani]. *Minbar. Islamic Studies*, 2019, no. 12, pp. 775–796. (In Russian).

**About the author:** Aidar M. Gainutdinov is a Cand. Sc. (Philology), Senior Research Fellow of the Department of Historical and Cultural Heritage of the Peoples of Tatarstan, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); aydargm@yandex.ru

*Received June 2, 2020* *Accepted for publication November 02, 2020*
*Published November 25, 2020*

*Гайнетдинов А.М.* Ризаэддин Фәхреддин Мәрҗанинең
кайбер ялгышлары хакында

# РИЗАЭДДИН ФАХРЕДДИН О НЕКОТОРЫХ ОШИБКАХ Ш. МАРДЖАНИ

***А.М. Гайнутдинов***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*aydargm@yandex.ru*

Выдающийся татарский ученый, богослов, муфтий Ризаэддин Фахреддин, хотя и не учился у ученого Шигабутдина Марджани, получил много знаний через его книги. В своем фундаментальном труде *«Асар»* («Произведения») он посвятил ему 50 страниц, на которых представлена обширная информация о его родословной, личности, детях, внешности, наставниках, учениках, книгах, ошибках и т.д. По мнению Ризаэддина хазрата, Марджани был самым первым представителем мусульман России, затронувшим в своих исследованиях деятельность шайхелислама Ибн Таймии. Фахреддин как кропотливый историк и богослов всегда пытался достичь истины. Он не слепо доверял словам Марджани, а сам изучал каждый интересовавший его вопрос. Несмотря на то, что мнение столь великого татарского ученого, как Шигабутдин Марджани, для него было авторитетным, он выявил у него некоторые ошибки. Это касалось вопросов вероубеждения ученого Ибн Таймии, которого некоторые обвиняли за его утверждения о телесности Бога и нахождении Его в конкретно определенном месте, а также за запрет посещать могилу пророка Мухаммада. Фахреддин, тщательно изучив его книги, выяснил, что ученого оклеветали и неправильно поняли. Он привел свои аргументы и слова других ученых по этому поводу. По мнению Фахреддина, Марджани допустил некоторые неверные высказывания в адрес Ибн Таймии. Причиной этому стало то, что Марджани не обращался непосредственно к трудам Ибн Таймии, а пользовался сочинениями мусульманского философа ад-Даввани и писателя ал-Яфиги, чьи книги он цитировал. Фахреддин учтиво указал на допущенные Марджани ошибки, одновременно попытавшись его оправдать. Фахреддин вслед за своим предшественником на посту муфтия Галимджаном Баруди изучал книги Ибн Таймии, соглашался с его взглядами, даже ставил этого ученого себе примером и не позволял никому несправедливо высказываться в его адрес.

**Ключевые слова:** Ризаэддин Фахреддин, Марджани, ошибки, Ибн Таймия, ад-Даввани, ал-Яфи‘и, *«Асар»*

**Для цитирования:** Гайнутдинов А.М. Ризаэддин Фәхреддин Мәрҗанинең кайбер ялгышлары хакында // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 284–292. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.284-292

**Сведения об авторе:** Гайнутдинов Айдар Марсилевич – кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела историко-культурного наследия народов РТ Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); aydargm@yandex.ru

*Поступила 02.06.2020* *Принята к публикации 02.11.2020*
*Опубликована 25.11.2020*